**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**2017 елда Ураза бәйрәмен һәм Корбан бәйрәмен уздыру көннәрен билгеләү турында**

«Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасында:
ай календаре һәм гадәткә кергән традицияләр нигезендә 2017 елның 25 июнен Ураза бәйрәме башлануга туры килә торган көн;
ай календаре һәм гадәткә кергән традицияләр нигезендә 2017 елның 1 сентябрен Корбан бәйрәме башлануга туры килә торган көн дип билгеләргә.

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 19 май
№ ПУ-401